Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**РЕШЕНИЕ №VI-3**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 19 декабре

2020-2021 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фаразлау планы турында

Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру максатларында, “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру турында Нигезләмә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2020-2021 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фаразлау планын кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына 2020-2021 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фаразлау планын (программасын) билгеләнгән тәртиптә тормышка ашыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 19 декабрендәге (-дагы) VI-3 номерлы карары белән расланды

# 2020-2021 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фаразлау планы (программасы)

## 1 бүлек. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру өлкәсендә сәясәтне тормышка ашыруның төп юнәлешләре һәм бурычлары

2020-2021 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фаразлау планы (программасы) Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Граждан кодексы, “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2006 елның 26 июлендәге “Көндәшлекне яклау турында” 135-ФЗ номерлы Федераль законнар, муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру мәсьәләләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру турында” 2017 елның 24 июлендәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының XX-10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә эшләнде.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру программасының төп юнәлеше ( текст буенча алга таба – муниципаль мөлкәт) муниципаль мөлкәт белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында хосусыйлаштыру процессының планлылыгын тәэмин итүдән гыйбарәт.

Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру программасы түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдереләчәк:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы икътисадының тулаем һәм аерым хуҗалык субъектлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;
- муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштырудан планлаштырылган барлык керемнәрнең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына үзвакытында һәм тулысынча керүе;
- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының милек структурасын оптимальләштерү һәм, нәтиҗә буларак, муниципаль мөлкәт белән

идарә итүгә бюджет чыгымнарын кыскарту, шул исәптән рентабельле булмаган объектларны тотуга һәм эксплуатацияләүгә чыгымнарны киметү;
- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы икътисадын һәм аның инфраструктурасын үстерү өчен инвестиция чараларын җәлеп итү;
- Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеген үстерүгә һәм бизнесны озак вакытка үстерүгә һәм яңа эш урыннары булдыруга юнәлтелгән нәтиҗәле милекчеләр формалаштыруга ярдәм итү.

2020-2021 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фаразлау планы (программасы) гамәлдә булу срогы дәвамында аңа Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелергә мөмкин.

Ел дәвамында хосусыйлаштырылмаган муниципаль мөлкәт объектлары киләсе елга фаразлау планына кертелә.

## 2 бүлек. 2020-2021 елларда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль мөлкәт объектлары исемлеге һәм сыйфатламасы

2020-2021 елларга хосусыйлаштыру программасы нигезендә түбәндәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру күздә тотыла:

| № п/п | Аталышы | Урнашу урынының адресы | Микъдары (данә) | Функциональ билгеләнеше | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | FIAT DUCATO автобусы, таныклау номеры (VIN)- Z7G244000AS012611, кузов (шасси), № Z7G244000AS012611, ак төстә. | Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп. | 1 данә | В класс М2 категориясендәге балаларны йөртү өчен махсус | Ирекле |

Хосусыйлаштыру программасын тормышка ашыру sale.zakazrf.ru электрон сәүдә мәйданчыгында урнаштырып аукцион уздыру юлы белән гамәлгә ашырылачак, шул исәптән биредә хосусыйлаштыру ысуллары һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның бәяләү эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә билгеләнгән башлангыч бәясе күрсәтелә.

Әлеге программада каралган хосусыйлаштыру шартлары турында карар кабул итү муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк.